РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
АЛЬМЕТЬЕВСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ ШӘҺӘРЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«15» ноябрь 2021г. г. Альметьевск № 49

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2013 елның 15ноябрендәге 116 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре территориясендә җир салымы турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре Уставының 29 статьясы нигезендә

Әлмәт шәһәре Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2013 елның 15 ноябрендәге 116 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре территориясендә җир салымы турында»гы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2014 елның 2 октябрендәге 141 номерлы, 2014 елның 19 ноябрендәге 151 номерлы, 2015 елның 6 маендагы 179, 2015 елның 20 ноябрендәге 13, 2016 елның 8 ноябрендәге 49 номерлы, 2018 елның 31 маендагы 122 номерлы, 2018 елның 15 ноябрендәге 126, 2019 елның 28 августындагы 166 номерлы, 2020 елның 12 мартындагы 189 номерлы, 2020 елның 28 августындагы 206 номерлы, 2021 елның 17 июнендәге 37 номерлы каралары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 3 пунктка түбәндәге эчтәлекле тугызынчы абзац өстәргә:

- «мәктәпкәчә һәм мәктәпкәчә белем бирүнең төп белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензия нигезендә эшләүче хосусый гомуми белем бирү учреждениеләре өчен мәгариф объектлары биләгән җир кишәрлекләренә карата учреждениеләр.»;

1.2. 3 нче пунктның унынчы абзацын унберенче абзац дип санарга.

2. Район башкарма комитетының Хокук идарәсенә (Ханнанова Ә. Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация сайтында урнаштырырга.

Зак. № 1352-200

3. Әлеге карарның 1 пункты рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм үз йогынтысын 2022 елның 1 январеннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә тарата.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны шәһәр Советының бюджет-финанс мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә (Мусин Р.Ф.) йөкләргә.

Шәһәр Башлыгы Т.Д. Нагуманов